ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2026 Олы Кайбыч ав. № 369

16:21:120101:1043 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларының тормыш эшчәнлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга туры китерү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 16:21:120101:1043 кадастр номерлы, 237кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Мәлки авыл җирлеге, Мәлки авылы, Үзәк ур.- «Шәхси ихтияҗлар өчен гаражлар урнаштыру» адресы буенча урнашкан универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча (кушымта) җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. 2026 елның 11 августында 11.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Мәлки авылы, Почта ур, 18 й. адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасында 16:21:120101:1043 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. 16:21:120101:1043 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты материаллары белән (текст һәм график өлеш) эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Мәлки авылы, Гагарин ур.,19 й..

3.1. 16:21:120101:1043 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

16:21:120101:1043 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Ю.В. Гайнуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 е. 29.07. 369 номерлы
карарына кушымта

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРОЕКТ**

№__________

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«_____»______________20__

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. 16:21:120101:1043 кадастр номерлы, 237 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Мәлки авыл җирлеге, Мәлки авылы, Үзәк урам - «Шәхси ихтияҗлар өчен гаражлар урнаштыру» адресы буенча урнашкан универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.А.Шәйдуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Территорияләрне үстерү департаменты Җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**